СОВЕТ МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

27.09.2017 | с. Русское Макулово | 39-157

Макыл авыл җирлеге территориясендә гражданнар үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы, «Макыл авыл җирлеге уставының 11 статьясы, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» Макыл авыл җирлеге Советының 2017 елның 19 сентябрендәге 38-152 номерлы карары, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» Макыл авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 19 июнендәге 50 номерлы карары нигезендә җирле референдум уздыру инициативасы хакында» Макыл авыл җирлеге башкарма комитетының 19.09.50 номерлы карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2017 елның 19 ноябренә Макыл авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

"2018 елда Макыл авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар юлламасы белән риза булырсызмы:

- Рус Макылы авылы Елга аръягы, Мәктәп, Тынычлык урамнары буйлап 2,5 км озынлыктагы юлларга вак таш түшәү;
- Клянчино авылындагы зират коймаларын тотып алу;
- Исаево авылында урамнарны яктырту фонарьларын сатып алу һәм урнаштыру;
- Сеитово авылында урамнарны яктырту фонарьларын сатып алу һәм урнаштыру.

ӘЙЕ ЮК".

3. «Волжская новь» район газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Макыл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге башлыгы А. И. Матвеева